СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2017 ел** **№51**

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Уставына таянып, Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә әлеге территориядә мәҗбүри түләүгә җир салымы билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Җир салымының кадастр бәясеннән салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

2.1.гомуми файдаланудагы 1 - 3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 процент;

2.2. авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 процент;

2.3. Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент;

2.4. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә карата 0,08 процент;

2.5. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,08 процент;

2.6. җитештерү һәм административ биналар, төзелешләр, сәнәгать, коммуналь хуҗалык корылмалары, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, торак пунктлар җирләре составында сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,2 процент;

2.7. башка җир кишәрлекләренә карата .1,5 процент.

3. Салым ташламаларын түбәндәгечә калдырырга:

3.1. 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

3.1.1. муниципаль учреждениеләргә - мәйданнар, урамнар, машина юллары, автомобиль юллары, яр буе, парклар, аллеялар, скверлар билгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата;

3.1.2. оешмалар һәм учреждениеләргә - зиратлар, үләт базлары, граждан күмүләре, каты көнкүреш калдыклары полигоннары билгән җир кишәрлекләренә карата;

3.2. Җир салымын түләүдән өлешчә азат итү рәвешендә:

3.2.1. Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан финанслана торган Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә җирнең кадастр бәясенең 0,52 проценты күләмендә салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә;

3.3. Шәхси ярдәмче хуҗалык өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата салым түләүдән салым түләүчене сайлау буенча бер җир кишәрлеге өчен тулысынча азат итү рәвешендә:

3.3.1. Ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә, салым чоры дәвамында ирекле янгын сүндерү командалары (дружиналары) составында янгыннарны сүндерүдә турыдан-туры катнашу шарты белән.

4. түбәндәгене билгеләргә:

Салым чоры дип календарь ел танылa.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa.

Салым түләүчеләр - салым түләү оешмалары өчен җир кишәрлегенең кадастр бәясенең беренче, икенче һәм өченче квартал узганнан соң икенче айның 15 көненнән дә соңга калмыйча кадастр бәясенең процент ставкасы күләмендә аванс түләүләре башкарыла. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

5. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә «Арча хәбәрләре» район газетасында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

6. С 01.01.2018 Шушмабаш авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын танырга:

- «Җир салымы турында» 2016 елның 1 ноябрендәге 30 номерлы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карарын;

- «Җир салымы турында» 2016 елның 1 ноябрендәге 26 номерлы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 30 июнендәге 43 номерлы карарын.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ОГРН 1121690000210 ИНН 1609012678
СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ